# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 28 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

"Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында" 2008 елның 2 августындагы 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 8 (I өлеш); 2009, № 6) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

"4) 2011 елның 1 гыйнварыннан 2013 елның 1 июленә кадәр эксплуатациягә кертелгән, техник документация нигезендә машина урыны саны кимендә 150 берәмлек булган автомототранспорт чараларын куеп торуның күпкатлы һәм җир асты урыннарында (парковкаларда) автомототранспорт чараларына куеп тору урыннары (парковкалар) хезмәте күрсәтүләрдән керем тиешле хисап (салым) чорына керемнең 100 процентын тәшкил иткән оешмалар өчен.";

2) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**"2 статья**

Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пункты нигезләмәсе 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалта һәм 2011 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2011 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 8 мае
№ 14-ТРЗ